Национальная библиотека
Республики Татарстан

# ӘДӘБИЯТ – ЗАМАН КӨЗГЕСЕ

Хәзерге заман татар
әдәбиятына
багышланган методик-библиографик
ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2022

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**
**Ә 26**

Төзүчесе З.Ә.Җамалиева
Мөхәррире И.Г.Һадиев

**Ә 26** Әдәбият – заман көзгесе: хәзерге заман татар әдәбиятына багышланган методик-библиографик ярдәмлек /Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. З.Ә.Җамалиева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2022. – 16 б.

Методик ярдәмлек хәзерге заман татар әдәбияты белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Бирелгән материалларны семинарлар, китап күргәзмәләре оештыруда, викториналар, фикер алышулар һәм башка мәдәни чаралар үткәрүдә файдаланып була.

**УДК 025.5**
**ББК 78.37**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2022;
© «Милли китап» нәшрияты, 2022.

# Кереш сүз

Гасырлар белән аерылса да, XX – XXI йөзләр чиге әдәби барышын ике этапка бүлү шактый кыенлык тудыра. Чөнки 1986 елдан демократик реформалар белән татар мәдәниятендә башланып киткән масштаб-лы үзгәрешләр 2001 елга чыккач та дәвам итә.

Әмма XX гасыр ахырына татар әдәбияты үзенең кыйбласын таба: милләт темасы үзәккә куела, совет идеологиясен һәм тоталитар режимны тәнкыйтьләү, советчыл мифны җимерү һәм кызыл идеологияне абсурд чигенә җиткереп сурәтләү, үткән, хәзерге һәм киләчәккә нисбәтле хакыйкатьне эзләү, тормышны камилләштерү мөмкинлекләрен барлау алгы планга чыга.

XXI гасырга чыккач та татар әдәбияты XX гасыр ахырында ачыклаган магистраль юлы буйлап камилләшү чорын кичерә. Әмма, эчтәлектән бигрәк, эзләнүләр форма өлкәсенә үтеп керәләр, татар әдәбиятының тормышны кабат тергезү мөмкинлекләре, жанрлар системасы, сурәтләү арсеналы үзгә нигезләргә урнаша. Хәзер инде форма үзгәрешләре әдәбиятта эчтәлек ягында барган үзгәрешләрне тагын да ачыграк күзаллау мөмкинлеге бирә. Шуңа күрә XXI гасыр башын татар әдәбиятының яңа кыйбла билгеләү, форма ягыннан камилләшү, эстетик элитарлыкка омтылу этабы дип карарга кирәк.

Бүгенге татар әдәбияты бай һәм күпкырлы. Китапханәчеләрнең бурычы – аны өйрәнү һәм китап укучыларга җиткерү. Бу максаттан чыгып без сезгә методик ярдәмлек тәкъдим итәбез.

Ярдәмлектә бирелгән материаллар китапханәләрдә төрле чаралар: әңгәмәләр, китап күргәзмәләре, семинарлар, китапларга күзәтү, викториналар үткәрергә булышлык итә ала.

Әлеге кулланма татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлекләрендә эшләүче китапханә хезмәткәрләре, гомумән, татар әдәбияты белән кызыксынучылар өчен төзелде.

Үзәк китапханәләрдә район һәм шәһәр китапханәчеләре өчен укулар оештыру максатка ярашлы булыр иде. Укулар семинар рәвешендә уздырылса, әйбәт нәтиҗә бирер дип уйлыйбыз. Шундый семинарның якынча эш тәртибен дә тәкъдим итәбез.

# Әдәбият – заман көзгесе

**(Китапханәчеләр семинары)**

1. Бүгенге татар әдәбиятында жанрлар һәм темалар төрлелеге (Әдәбият белгече чыгышы).
2. Әдәбиятта яңа исемнәр.
3. Хәзерге заман татар әдәбияты белән эшләү алымнары (Методик киңәшләр).
4. Татар язучыларының әсәрләрен укучыларга җиткерү буенча эш тәҗрибәсе.
5. Күрсәтмә чара.

# Әдәбият исемлеге


1. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Рахмани. – Казан: Фолиант, 2021. – Т. 8 : 2001–2020 еллар / фәнни мөх-ре: Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов. – 2021. – 740 б.
2. Даутов Г. Әдәбият – милли көрәш коралы ул: (хәзерге татар әдәбияты нинди хәлдә?) / Г. Даутов // Мәдәни җомга. – 2010. – 9 июль. – Б. 29.
3. Зәйдулла Р. Әдәби хәрәкәттә бәрәкәт бармы?: (хәзерге татар әдәбияты һәм татар прозасы тур.) // Мәдәни җомга. – 2011. – 3 июнь (№ 22). – Б. 9.
4. Кәбиров М. Үзеңне түбәнсетү: (хәзерге татар әдәбияты, әдәби тәнкыйть, нәшриятлар эше һәм Г.Тукай премиясе тур.) // Ватаным Татарстан. – 2019. – 5 июль (№ 95). – Б. 18.
5. Хатипов Ф. Әсәрләребезгә ни җитми?: (хәзерге татар әдәбияты тур.) / Ф. Хатипов // Казан утлары. – 2012. – № 9. – Б.134–138.

# Семинар үткәрү уңае белән «Язучы һәм заман» дигән китап күргәзмәсе ясарга тәкъдим итәбез

**1нче бүлек: «Тарихи тема»**

1. Әмирханов М. Бибимәмдүдә абыстай. – Казан: Идел-Пресс, 2019. – 183 б.
2. Әмирханов М. Дөя муены: повесть, хикәяләр. – Казан: Идел-Пресс, 2013. – 286 б.
3. Әмирханов М.  Олуг Мөхәммәд: романнар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 427 б.
4. Әмирханов М. Казан-йорт: тарихи романнар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 543 б.
5. Бәйрәмова Ф. Гөләйза: тарихи роман. – Казан: Аяз, 2018. – 311 б.
6. Бәйрәмова Ф. Күчем хан: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 288 б.
7. Бәйрәмова Ф. Һиҗрәт: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 558 б.
8. Имамов В. Казан дастаны: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2005. – 239 б.
9. Имамов В. Сайланма әсәрләр: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2018. – Т.3. – 575 б.
10. Имамов В. Сайланма әсәрләр: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018 – Т.4. – 499 б.
11. Имамов В. Сөләйман солтан: тарихи кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 223 б.
12. Имамов В. Утлы дала: тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2012. – 759 б.

**2 нче бүлек: «Милләт язмышы»**

1. Бәйрәмова Ф.  Милләт язмышы: фәнни-популяр язмалар. – Казан: Аяз, 2020. – 583 б.
2. Дәүләтшин З. Милләт өчен җан атып… – Казан: Школа, 2020. – 210 б.
3. Мансуров З. Милләтпәрвәр// З.Мансуров. Гамьне яктырткан ямь. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – Б. 16.

4. Сабиров И. Ныгый бара татарлыгым… – Казан, 2020. – 175 б.
5. Фәйзуллин Р. Әрнү // Р.Фәйзуллин. Яңа гасыр иртәсе: яңа шигырьләр. – Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 21.
6. Харис Р. Бер туңам, бер янам // Р.Харис. Сандугачлар тынган вакыт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 70.
7. Харис Р. Татар атлары // Казан утлары. – 2020. – №5. – Б.168.
8. Юзеев И. Ике йөз елдан соң инкыйраз // И.Юзеев. Мәңге ян, күңел! – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 271.
9. Юсупов Р. Милләтебез иминлеге сагында. – Казан: Сүз, 2020. – 558 б.

**3 нче бүлек: «Туган телгә мәхәббәт»**

1. Акмал Н. Туган тел // Н.Акмал. Күзләремнең төсе үзгәрмәде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б.15.
2. Акмал Н. Туган тел турында // Н.Акмал. Күзләремнең төсе үзгәрмәде. – Казан: Татар кит. нәшр., 2004. – Б. 26.
3. Иксанова И. Туган телемә // И.Иксанова. Гомер сурәте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 112.
4. Мансуров З. Киек каз юлы // З.Мансуров. Гамьне яктырткан ямь. – Татар. кит. нәшр., 2020. – Б.17.
5. Миңнуллин Р. Көндезге Казан // Казан утлары. – 2018. – № 8. – Б.4.
6. Үз җиремдә – үз телем. – Казан: Халкыбыз мирасы, 2021. – 309 б.
7. Шагыйрьҗан Л. Туган телгә мәдхия /Л.Шагыйрьҗан. Ни даулыйсың, йөрәк? – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – Б.135.
8. Шагыйрьҗан Л. Үз телеңдә кал! / Л.Шагыйрьҗан. Ни даулыйсың, йөрәк? – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – Б. 230.
9. Юсупов Р. Туган тел – милләтнең нигезе = Родной язык – фундамент нации. – Казан: Слово, 2021. – 254 б.

# Китап күргәзмәсенә күзәтү

**«Тарихи тема»**

Милли үзаң уяну, халыкның үз тарихы-тамырлары белән кызыксынуы арту тарихи романнар күпләп язылуга этәргеч бирә. XX гасыр ахырында активлашкан бу агым Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Батый хан һәм Ләйлә», Вахит Имамовның XIII гасыр вакыйгаларын тергезгән «Утлы дала», «Казан дастаны», «Карабәк», Рабит Батулланың «Мур кырылышы», «Апуш–Тукай», «Күк капусы ачылганда», «Җимерелгән бәхет», Рөстәм Галиуллинның «Васыять», Айгөл Әхмәтгалиеваның «Туташ», Марат Кәбировның «Шамил» һ.б.романнарында, Рабит Батулланың «Соңгы сөннәт», «Казан астым Казансу буенда», «Бәдәлче», Ркаил Зәйдулланың «Илбәк» кебек хикәяләрендә дәвам итә.

Язучылар татар тарихындагы күренекле, билгесез яки яшерелгән, бүген дә бәхәсле булып кала торган вакыйгаларга мөрәҗәгать итәләр, аларга реконструкция ясыйлар, укучыга милли каһарманнар, шанлы вакыйгалар, тарихи хәтердән алып ташланган хәлләр турында сөйлиләр.

Әмма татар әдәбиятында тарихи әсәрләрнең, нигездә, татар укучысына гына адреслануын, әдәби эшләнеше ягыннан заман әдәбиятына түгел, XX гасыр дөнья әдәбиятына йөз тотуын, публицистика белән фәнни башлангыч көчле бирелеп, гомумиләштерелгән бәянең язучы монологы төсен алуын да әйтергә кирәк.

Марат Әмирхановның XXI гасыр башында тарихка әдәби бәя бирүче иң актив язучы булуын әйтергә кирәк. Язучының «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», «Тәхетсез патша» кебек әсәрләрендә татар тарихының аерым бер сәхифәләре, бигрәк тә Казан ханлыгының яшәеше һәм җимерелүе белән бәйле вакыйгалар тасвирлана. «Тояк эзе», «Ир-Мамай» романнары исә укучыны Алтын Урда заманнарына алып китә. Иҗатының лейтмотивы – ил язмышының әйдаманнар язмышы белән тыгыз үрелгән булуын ассызыклау – язучыга төрле катлаулар тормыш-яшәешен детальләп тергезергә мөмкинлек бирә.

Марат Әмирханов соңгырак чорларга да бик теләп мөрәҗәгать итә: «Бибимәмдүдә» повесте – Габдулла Тукайның әнисенә, «Зиннәтулла хәзрәт» – бабасына, «Саҗидә» һәм «Газизә» повестьлары – апаларына, «Зәйтүнә» – сөйгән ярына багышланган әсәрләрдән.

## «Милләт язмышы»

Татар әдәбиятында милләт язмышы темасы XX гасыр дәвамында өстенлекле булып кала, яңа гасырга чыккач та эчтәлек ягыннан яңарыш шушы тема чикләрендә башкарыла. XXI гасыр башы татар шигърияте вәкилләреннән Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Мансуров, Айдар Хәлим һ.б. шагыйрьләр иҗатында милләт язмышының мөһимлеге һәрдаим ассызыкланып килә. Илдар Юзеев «Гасыр кичкән чакта...» шигырендә болай дип яза:

«Син каян? – дип сорый Киләчәгем.
«Татар яши!» – дигән өйдән мин.
Ниләр күреп, ниләр кичерсәм дә,
Аерылмам шушы көйдән мин!».

Ягъни шагыйрь татар әдәбиятының гасырлар чиген кичкәндәге вазифасын татар көен көйләү дип билгели. Шул ук вакытта милләт сакланырмы, яшәрме дигән сорауга аның җавабы анык түгел, «бетәрме, яшәрме – ике йөз елдан соң татарлар?» «иртәгә яшәрме татарлар?» соравын ул халык күңелендәге борчу буларак калкыта. Илдар Юзеевның «Сине көтә, мине көтә», «Илне көтә инкыйраз» дип кисәтүче лирик герое, XX гасыр башы татар шагыйрьләре иҗатындагы кебек үк, милләтне саклау өчен аны йокыдан, торгынлыктан, битарафлыктан уяту кирәклеген әйтә.

Һәр татар шагыйре, язучысы иҗатында шушы – милләт язмышы хакындагы ваем, гамь сизелеп тора. Бигрәк тә шигърият иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерүче җитез-оператив төр булудан туктамый. Мәсәлән, Равил Фәйзуллинның Тукай яшәгән Болгар номерларын җимерүгә кагылышлы «Әрнү» шигыре языла. Шагыйрь бу гамәлне «Тукайны сату», татар мәдәниятен һәм тарихын сату буларак бәяли: «Без Тукайны саттык!»... Дөресрәге, «Үзебезне саттык...Күпмегә?».. Равил Фәйзуллинның «Саклыйк республиканы!» шигыре Нурихан Фәттахның васыятен укыганнан соң иҗат ителә.

## «Туган телгә мәхәббәт»

Татар поэзиясендә иң күп шигырьләр туган телгә мәхәббәт, аның үсүенә өмет белән сугарылган. Матур романтик текстларның берсе – Илсөяр Иксанованың «Туган телемә» шигыре. Шигырьнең һәр строфасында туган телне ярату һәм аның киләчәгенә өмет яңгырый, әмма кинәт кенә үзгә кисәтү пәйда була:

«Мең аһәңле дәрьяларның бер дулкыны,
Саклап тора, йотам диеп мең упкынны?»

Шул рәвешле, туган тел турындагы, әмма күтәренке-шатлыклы аһәңдә иҗат ителгән шигырьләрдә дә ниндидер яшерен куркыныч барлыгы сиземләнә, еш кына ул хәтергә төшерелә торган үткән-советчыл чынбарлык белән бәйләп куела. Бу бигрәк тә дога жанр формасына мөрәҗәгать итү аша башкарыла, әлеге дога иң өметсез минутларда да күңелдә ышанычны сакларга ярдәм итә.

Ә инде тел мәсьәләсе 2017 елның көзеннән кискенләшкәч, мондый шигырьләрнең пафосы да тамырдан үзгәрә. Мәсәлән, Равилә Шәйдуллинаның «Ай тотылган төнне йокламадым..» шигырендә милләтнең вәкиле булган укучыга мондый эндәш җиткерелә:

«Тотылган ай, тышауланган байтал,
Тышауланган ана телебез.
Әй, татарым, әллә мескен айдай
Тышаулandык инде үзебез!»

Әлеге юлларда XX гасыр башындагыча, 1990 еллардагыча ук милләтне берләштерергә,«тышауларны өзәргә» чакыру ярылып ята.

Роберт Миңнуллинның үзирония белән язылган:

«Татарларның башкаласы
Казаныбызда хәтта
Татар телен белмәсәң дә
Яшәп була рәхәттә...» кебек тезмәләре дә сызлану катыш чарасызлык дулкынында. 2019 елның 10 сентябрендә булып үткән фаҗигагә бәйле, Альберт Разинга багышлап язылган «Удмурт яна» шигырендә шагыйрь татар теле язмышын кайгырткан риторик сорау белән янәшә, әйтерсең, шушы аяныч хәлгә тагын бер тапкыр бөтен кешелекнең игътибарын җәлеп итәргә омтыла: «Ник үләргә тиеш безнең телләр?/Ник бетәргә тиеш әле без?/Яшәү белән үлем арасында/Безнең телләр, безнең хәлебез!».

**«Драма әсәрләренә күзәтү»**

Әдәби процесста мөһим урын алып торган драматургия җәмгыятьтәге икътисади һәм мәдәни үзгәрешләргә аваздаш үсеш-үзгәреш кичерә, халыкның рухи ихтыяҗына сәхнә теле белән җавап бирүнең яңадан-яңа юлларын, формаларын эзли. Бу исә тематик төрлелеккә, әдәби-эстетик эзләнүләрнең төрле яссылыкта алып барылуына китерә. Яңа гасыр башында Туфан Миңнуллин, Рабит

Батулла, Фоат Садриев, Ризван Хәмид кебек өлкән буын һәм Зөлфәт Хәким, Аманулла, Рәдиф Сәгъди, Данил Салихов, Мансур Гыйләҗев, Фәнәвил Галиев, Гафур Каюмов, Ркаил Зәйдулла, Шамил Фәрхетдин һ.б. кебек урта буын драматурглар актив иҗатта кала. Моңа кадәр әдәбиятның башка төрендә уңышлы эшләгән Эсфир Яһүдин, Хәбир Ибраһим, Ләбиб Лерон, Равил Бохараев, Зиннур Хөснияр, Нәзифә Кәримова, Зөләйха Минһаҗева, Салават Юзеев, Айгөл Әхмәтгалиева һ.б. драматург буларак та танылу ала. Ә инде Илгиз Зәйниев, Равил Сабыр, Раилә Мөхсинова, Сөмбел Гаффарова, Йолдыз Миңнуллина, Нәфисә Исмәгыйлева, Артур Шәйдуллин исемнәре сәхнә әдәбиятына яңа буын килү турында хәбәр итә.

Дәвер куйган сорауларга җавап эзләп, драматургия яшәешнең төрле якларына мөрәҗәгать итә, иҗтимагый, милли һәм шәхси мәсьәләләр заманча яссылыкта, темативлар байлыгында чагылыш таба. Кеше бәхете, яшәү һәм үлем, гомер агышы, яшәү мәгънәсе турында уйланып, драматурглар ерактагы һәм якындагы тарихны, совет җәмгыятендәге, тоталитаризм чорындагы гаделсезлекләрне, әфган һәм чечен сугышлары кайтавазын, авылларның бетүе һәм глобальләшү күренешен, җәмгыятьтә барлыкка килгән яңа гадәтләрне, гомумкешелек кыйммәтләренең кимүе һәм шәфкатьсезлек билгеләренең арту сәбәпләрен, милли традицияләргә янаган курдәүләтенең Казан ханлыгын басып алуы фаҗигасе, мәңге төзәлмәслек яра булып, гасырлар дәвамында әдипләрнең игътибар үзәгендә тора. Мәдинә Маликованың «Сөембикә», Ркаил Зәйдулланың «Соңгы татар» трагедияләрендә әлеге тарихи вакыйгалар урын ала.

Бөек Ватан сугышы вакыйгалары татар драматургиясендә гыйбрәтле хәл-күренешләр, катлаулы язмышлар урын алган пьесаларны мәйданга чыгара: Зөлфәт Хәкимнең «Телсез күке», «Бит», «Легионер», Рәдиф Сәгъдинең «Бакчасарай гөлләре», Данил Салиховның «Узып барышлый», «Өзелгән йөзем», Равил Сабырның «Абага алмасы ачы була» һ.б. пьесаларда урын алган сугыш кайтавазы бөтен халык фаҗигасен, аның аерым кеше, милләт тормышында чагылышын ачуга хезмәт итә. Әсәрләрдә, сугыш факторларыннан бигрәк, ул алып килгән кайгы-хәсрәт, җимерелгән язмышлар алгы планга чыга. Сугыш вакыйгаларына бәйле рәвештә милләт язмышы, кешенең рухи иреге-азатлыгы мәсьәләләре калкытып куела. Пьесаларда еш кына сызлану фәлсәфәсе урын алып, кеше җанының бәргәләнүләре ачыла һәм шуның аша сугыш

алып килгән фаҗигаләрне булдырмау юллары эзләнә.

Сәхнә әдәбиятында жанр төрлелеге турында сүз алып барганда, балалар өчен язылган пьесаларның арта баруын билгеләп үтәргә кирәк. Бу өлкәдә Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Рәдиф Сәгъди, Рафис Корбан, Ләбиб Лерон, Мансур Гыйләҗев, Хәлим Җәләй, Зиннур Хөснияр, Шамил Фәрхетдинов, Ркаил Зәйдулла, Рүзәл Мөхәммәтшин һ.б. уңышлы эшләп килә. Балалар аудиториясенә атап язылган пьеса җыентыклары буларак Шамил Фәрхетдиновның «Әкият турында әкият», Хәлим Җәләйнең «Шәрә бүре», Илгиз Зәйниевның «Бәби» китаплары дөнья күрде. Равил Бохараевның татар халык йолалары, ышанулары нигезендә язылган «Тимер борчак» әкият-пьесасы үзәгендә яхшылык-явызлык көрәше ята, Шүрәле, Дию, Су иясе, Юха елан кебек мифологик образлар кешеләр белән катлаулы мөнәсәбәтләрдә тасвирлана. Пьесада Мәхәббәт, Гаделлек, Хезмәт, Миһербанлык кебек изге кыйммәтләр өчен җитди көрәш бара, мифологик күренешләр, халык авыз иҗаты әсәрләре, Габдулла Тукай шигырьләре, фантастик һәм чынбарлык катламнары үзара бәйләнеп, бербөтен идеягә китерә. Рүзәл Мөхәммәтшинның «Өрә белмәгән көчек» әсәрендә йорт һәм кыргый хайваннарга бәйле гыйбрәтле вакыйгалар аша һәркемнең туган теле булу һәм аны белүнең кирәклеге турында мәгънәле тамаша тәкъдим ителә.

# ӘДӘБИЯТЛЫ ХАЛЫК – ГОРУР ХАЛЫК
## (Викторина үткәрү өчен сораулар)

**1. Соңгы елларда тарихи темага нинди әсәрләр иҗат ителде?**

(Мөсәгыйть Хәбибуллин «Батый хан һәм Ләйлә», Вахит Имамов «Утлы дала», «Казан дастаны», «Карабәк», Рабит Батулла «Мур кырылышы», «Апуш-Тукай», «Күк капусы ачылганда», Марат Әмирханов «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», «Тәхетсез патша» һ.б.).

**2. «Җирән казакның камчысы инде Фагыйлә карчыкның җилкәсендә уйный. Аклы күлмәгенә канлы камчы эзләре бәреп чыкты. Фагыйлә, аңын җуеп чирәм өстенә егылуга, Зөһрәне ике казак, аңсыз әнисе куенынннан сөйрәп алып, ат арбасына, үкереп елап торган уллары янына аттылар». – дигән юллар Равилә Шәйдуллинаның нинди әсәреннән алынган?**

(«Карт шомырт хатирәсе»ннән).

**3. Зифа Кадырованың нинди әсәрләре сәхнәләштерелгән?**

(«Язмыш сынавы», «Сагынырсың мин булмам», «Синсез килгән язлар», «Бәхеткә юл кайдан?», «Көтеп узган гомер»).

**4. Илемнән дә, көнемнән дә**
**Өметне өзгән чагым.**
**Мин түзмәсәм, кемнәр түзәр,**
**Дип кенә түзгән чагым. – дигән юллар Марат Кәбировның нинди шигыреннән алынган?**

(«Әллә нинди сәер чагым»).

**5. Г. Тукай иҗатын максатчан өйрәнүчеләр арасында кемнәрне атап үтә аласыз?**

(Тәлгать Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов, Резеда Ганиева, Фоат Галимуллин, Венера Әминева, Зөфәр Рәмиев, Фәрит Яхин, Рәмил Исламов, Нурфия Йосыпова һ.б.).

**6. Соңгы елларда Габдулла Тукай премиясенә лаек булган язучыларны атап үтегез.**

(Розалина Шаһиева, Камил Кәримов, Факил Сафин, Лирон Хәмидуллин, Ләбиб Лерон).

**7. Әдәбият өлкәсендә нинди тәнкыйтьчеләрне беләсез?**

(Тәлгать Галиуллин, Азат Әхмәдуллин, Фоат Галимуллин, Әлфәт Закирҗанов, Фәрит Яхин, Нурфия Йосыпова, Рифә Рахман һ.б).

**8. Татар әдәбияты өлкәсендә кемнәр исемнәрен йөрткән премияләрне беләсез?**

(Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Шиһабетдин Мәрҗәни, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Һади Атласи, Фәннур Сафин, Шәйхи Маннур, Кояш Тимбикова, Рафаил Төхфәтуллин һ.б.).

**9. Кайсы шагыйрьләргә «Татарстанның халык шагыйре» дигән исем бирелде?**

(Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев, Шәүкәт Галиев, Ркаил Зәйдуллин, Зиннур Мансуров, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Илдар Юзеев, Фәнис Яруллин).

# Эчтәлек

1. Кереш сүз ........................................................................... 3

2. Әдәбият – заман көзгесе (китапханәчеләр семинары)............ 4

3. «Язучы һәм заман» дигән китап күргәзмәсе ясарга тәкъдим итәбез ........................................................................... 5

4. Китап күргәзмәсенә күзәтү................................................... 7

5. Әдәбиятлы халык – горур халык (викторина үткәрү өчен сораулар) ........................................................................... 12

Басарга кул куелды 15.07.2022. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 75 данә. Заказ № 465.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86 йорт.

Подписано в печать 15.07.2022. Формат 60х84 1/16.
Тираж 75 экз. Заказ № 465.
Национальная библиотека Республики Татарстан,
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.
420015, Казан шәһәре, К.Маркс ур., 36.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 36.